ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАШКИЧҮ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАРЫ

№ 29 Кече Урыссу ав. 2023 елның 17 ноябре

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Советының 04.07.2018 № 13 Карары белән расланган, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Ташкичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлеге Советы карар кабул итә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлеге Советының 04.07.2018 № 13 Карары белән расланган, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Ташкичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 12 статьясындагы 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җирлекләрнең генераль планнары, шәһәр округларының генераль планнары проектларына һәм җирлекләрнең генераль планнарына, шәһәр округларының генераль планнарына үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проектлар буенча иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар (алга таба - иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар), Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 28 статьясындагы 3.1 һәм 3.2 өлешләрендә билгеләнгән очраклардан тыш, муниципаль берәмлекнең һәр торак пунктында уздырыла».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Ташкичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталы составында «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Ташкичү авыл җирлеге башлыгы Р.К.Валеев